КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 29 март г.Казань № 205

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гарантияләр фонды» коммерциягә карамаган оешмасына чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 9 июнь, 438 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 сентябрь, 875 нче; 2019 ел, 15 май, 397 нче; 2021 ел, 19 апрель, 256 нчы; 2021 ел, 5 июль, 544 нче; 2022 ел, 1 март, 187 нче; 2022 ел, 22 июль, 712 нче; 2023 ел, 30 гыйнвар, 69 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм» төбәк проекты чараларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы Гарантияләр фонды» коммерциягә карамаган оешмасына чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

2 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының (алга таба – дәүләт программасы) «2018 – 2025 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы (алга таба – ярдәмче программа)» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү» төбәк программасы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның җиденче абзацында «2017 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы» сүзләрен «2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның «мөһер» сүзеннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Идарә итүче компанияләрнең һәм (яки) сәнәгать (индустриаль) парклары резидентларының инфраструктурасын үстерү өчен аларга заемнар бирү максатларында кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 31 май, 417 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 6 декабрь, 1167 нче; 2022 ел, 16 август, 837 нче; 2022 ел, 16 ноябрь, 1222 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Идарә итүче компанияләрнең һәм (яки) сәнәгать (индустриаль) парклары резидентларының инфраструктурасын үстерү өчен аларга заемнар бирү максатларында кече һәм урта эшмәкәрлеккә (крестьян (фермер) хуҗалыкларын кертеп) дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыру өчен «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм анда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү» төбәк программасындагы «Паркларның

(индустриаль), сәнәгать мәйданчыкларының коммуналь һәм юл инфраструктурасы объектларын, биналарын, төзелмәләрен, корылмаларын төзүгә, модернизацияләүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә заемнар формасында ярдәм күрсәтелде» чараларын гамәлгә ашыруга бәйле «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлекне яклау фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.»;

10 пунктка «мөһер» сүзеннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карар (2024 елның 1 июненнән үз көченә керә торган 1 пунктның җиденче абзацыннан, 2 пунктның дүртенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин